КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 октябрь

г.Казань

№ 1072

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 858 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының торак-коммуналь өлкәсендә җәмәгатьчелек контроле механизмнарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны финанслар белән тәэмин итү өчен

коммерциягә карамаган оешмага Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

9 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Сайлап алуда катнашучы сайлап алу үткәрү турында белдерү урнаштырылган ай алдыннан килгән айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

10 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы;»;

11 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү урнаштырыла торган айга кадәрге айның 1 нче көненә карата салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган белешмә кәгазе;»;

23 пунктта:

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар кертү сроклары һәм формалары;

«субсидия алучының, субсидияләр алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29. Субсидия алучы Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк рәвешләренә кушымта итеп бирелә торган рәвешләр буенча, квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 5 нче көненә кадәр субсидияләр бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.»;

30 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга;

32 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«32. Килешүдә күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә субсидияләр алучы ирешмәгән очракта, субсидия шушы Тәртипнең 33 пункты белән билгеләнә торган күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына шушы эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.»;

34 һәм 35 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Министрлык субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен (шул исәптән бу Тәртиптә һәм килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерә.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

35. Субсидия субсидия алучы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы һәм (яисә) акчаны алучы белән субсидия алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә алучы тарафыннан шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе нигезендә акча алучы затлар тарафыннан бозылган очракта;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисапларны, шулай ук, әгәр килешү өстәмә хисаплар бирүне билгеләгән булса, өстәмә хисапларны тапшырмау.»;

38 пунктта «максатчан» сүзен «нәтиҗәле» сүзенә алмаштырырга.

түбәндәге эчтәлекле 39 пункт өстәргә:

«39. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

Тәртипнең кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Тәртипнең 9 пунктындагы җиденче абзацының һәм Тәртипнең кушымтасындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы егерме җиденче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин